ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## "Физик культура һәм спорт турында" Татарстан Республикасы Законының 24 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 10 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Физик культура һәм спорт турында" 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; 2012, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 1 – 2, № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 3), аңа түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

"4. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар спорт әзерлеге программаларын гамәлгә ашырганда үзләрендә спорт әзерлеге узучы затларның сәламәтлеген саклау өчен шартлар тудыралар, шулай ук спорт әзерлеге узучы һәм спорт әзерлеген гамәлгә ашырмый торган физкультура-спорт оешмасы белән хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы затлар белән алар спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда спорт әзерлеге узган вакытта, шул исәптән спорт әзерлеге буенча гамәлгә ашырыла торган программаларда каралган спорт ярышларында катнашу вакытында булган бәхетсезлек очракларын тикшерүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәләр. Күрсәтелгән бәхетсезлек очракларын тикшерү һәм исәпкә алу Федераль закон нигезендә башкарыла.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
вазыйфаларын вакытлыча башкаручы
Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2015 елның 2 июле
№ 52-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ